**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗАРЕЧЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423008, РТ, Нурлатский район п. Заречный,
ул. Черемшанская, д.5

**ЗАРЕЧНЫЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Чирмешән ур., 5нче йорт, ТР, Нурлат
районы, Заречный авылы, 423008

Телефон: 8 (84345) 38613, факс 38613 E-mail: Zarech.Nur@tatar.ru, сайт: http://nurlat.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Заречный пос. **КАРАР**

«14» октябрь 2022 ел № 12

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлегенең Заречный поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елның 26 октябрендә 17 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлегендә Дорожная урамы 15 адресы буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2022 елның 27 октябрендә 16 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлегенең Заречный торак пунктында авыл клубы бинасында Үзәк урамы 4 адресы буенча Новая, Заречная, Речная, Лесная, Үзәк, Чирмешән урамнарындагы йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2022 елның 17 октябрендә 18 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлегендә Яшьләр урамында яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын уздыру өчен Заречный поселогында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

5. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

6.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге Заречный поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм әлеге кертемнәрне түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- зиратны төзекләндерү;
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы тоту;
- көндезге яктырту лампаларын сатып алу һәм алыштыру;
- су алу корылмаларын тоту һәм ремонтлау.

« РИЗА»                «КАРШЫ».

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтына http://nurlat.tatarstan.ru урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Заречный авыл җирлеге башлыгы                Т.В Забойдулина